# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Карашам торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2022 елның 19 октябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә шушы сорау буенча 11 сәгать 00 минутта 2022 елның 19 октябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2023 елда Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Карашам торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидларыннан һәм күп балалы гаиләләрдән тыш, 500,00 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?

1. Автомобиль юлларын төзү, ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу, шул исәптән Карашам торак пунктында объектны техник паспортлаштыру;

2. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру;

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **89** кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә **51** кеше катнашты, бу **57,3%** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда **51** кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Карашам торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. 2023 елда үзара салым акчаларын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге территориясендә Карашам торак пунктында даими яшәүче һәр балигъ

булган, I группа инвалидларыннан һәм күп балалы гаиләләрдән тыш 500,00 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Автомобиль юлларын төзү, ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу, шул исәптән Карашам торак пунктында объектны техник паспортлаштыру;

2. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Карашам авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче

Г.Ф.Семахина